**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ**
**21.01.2014 ел.**

Казан ш.

**БОЕРЫК**
**№ 32-п**

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2012 елның 10 сентябрендәге 351-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын законнарга туры китерү, шулай ук җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар үткәрү процедурасының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2012 елның 10 сентябрендәге 351-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәнең 7.8 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«7.8. Әгәр Аукционда җиңүче лицензия проектларын һәм җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турындагы лицензия килешүен алганнан соң 30 көн эчендә әлеге документларның имзаланган проектларын Министрлыкка тапшырмаса, Министрлык җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында карарны юкка чыгару турында карар кабул итә.

Бу очракта, шулай ук Аукционда җиңүче файдалану хокукыннан баш тарткан очракта да, Аукционда җиңүче тарафыннан алдан кертелгән акча кире кайтарылмый.».

2. Хокукый тәэмин итү бүлеге (В.А.Тронин) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Т.М.Акчуринга йөкләргә.

Министр
А.Г.СИДОРОВ